Сабира Сталберг

# Филип туннельдә



aybagar

**Сабира Сталберг**

# Филип туннельдә

**Фазилә Насретдин тәрҗемәсе**
**Мария Виитасало рәсемнәре**

1 җиңел тел

aybagar

Хельсинки 2022

**Җиңел тел дәрәҗәләре**
**Дәрәҗә 1: Иң җиңел тел**
Дәрәҗә 2: Җиңелрәк
Дәрәҗә 3: Җиңел

Tatar, Cyrillic script
1. басма / edition

Швед телендә / Original:
Sabira Ståhlberg: *Filip i tunneln*
Тәрҗемә: Фазилә Насретдин
Translation: Fazile Nasretdin
Рәсемнәр / Illustrations: Maria Viitasalo

Эш төркеме: Альбина Самархан,
Камәр Яфай Ногманов,
Дәрия Самалетдин, Адилә Самалетдин

Мөхәррир: Лилия Дәүләт

© Сабира Сталберг 2022
© Фазилә Насретдин, тәрҗемә, 2022
© Мария Виитасало, рәсемнәр, 2022

Айбагар ▸ aybagar.eu
Хельсинки / Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-75-1 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-76-8 (Е-китап, PDF)

# Бүлем 1

Минем исемем Филип
һәм мин уйнарга яратам.
Бик күп компьютер
уеннары уйный беләм.
Телефонда булганнарны
һәрберсен уйный беләм.
Синең телефоныңда булганнарны
да уйный беләм. Ни әйтәсең?
Миңа ышанмыйсыңмы?

Әти әйтә, уйнауның файдасы юк.
Сабак уку яхшырак.
‒ Сиңа күп нәрсәләр өйрәнергә кирәк.
Үскәч, сиңа үзеңә һөнәр табарга кирәк.
Уеннар сиңа бернинди дә файдалы
нәрсәләр өйрәтми, ‒ дип әйтә әти.
Әтием киләчәк турында уйлый.

Әни ризык турында уйлый:
‒ Дөрес тукланырга кирәк, ‒ ди әни.
Әни салат ашарга кирәк ди.
Кыяр, томат һәм шундый яшелчәләр.
Мин күбрәк бәрәңге яратам.
Мин кыздырган бәрәңге яратам,
кетчуп һәм майонез белән.

Минемчә, ул иң тәмле ризык.
Ләкин иң яхшысы – уйнау.
Кичә телефоным ватылды.
Сүнде дә куйды.

‒ Филип, сиңа әле яңа телефон
сатып алырга кирәк, ‒ әти әйтә.
‒ Уеннары күп кенә булсын.
Мин андый телефон телим, ‒
җавап бирәм.

‒ Юк, ‒ ди әти.
‒ Җитәрлек күп уеннарың бар инде.
‒ Артык күп уйнау сәламәтлеккә
яхшы түгел, ‒ ди әни.
Әни белән әти яхшылар,
ләкин алар мине кайчак
аңламыйлар гына.

Мин чыннан даниләр турында
уйлаганны әбәй генә белә.
Ул мине тыңлый.
Без һәртөрле нәрсә
турында сөйләшәләбез.
Әбәй дә кайбер компьютер
уеннарын уйный белә.
Мин әбәйне яратам.

# Бүлем 2

Әле шәһәр уртасына керәбез.
Автобыз ачык яшел Опель.
Автоны әни йөртә.
Без шәһәр үзәгендәге
зур кибеткә барабыз.

Әти телефонда сөйләшә.
Ул әбәй белән озак сөйләшкәч:
– Ашыгырга кирәк, – ди.
– Өйләдән соң әбәй кунакка килә.

Автоны кибетләр астындагы
автопаркка калдырабыз.
Автопарк җир астында.
Аннан лифт белән менәбез.
Кибет кешеләр белән тулы.

– Бүген шимбә көн.
Атна ахырында һаман
кеше күп була, – ди әти.
Әни тирән итеп сулап ала.
– Тыгызлыкка чыдамыйм, – дип әйтә.
– Әйдәгез инде,
вакытыбыз күп юк.
Әбәй сәгать дүрттә килә, – әти әйтә.

– Бер телефон алырга өлгерәбез инде.
Ул күп вакыт алмый, – әни җавап бирә.

– Әни, алай түгел.
Мин төрлеләрен карарга телим.
Телефон белән ниләр эшләп була,
анысын белмичә сайламыйм.

– Әбәй өчен туңдырма да алабыз, –
әти искә төшерә.
– Аны онытмагыз!

Әбәй туңдырма бик ярата.
Каһвә, булкаларны яратмый.
Яшел чәйне һәм
туңдырманы гына ярата.

Әбәй кунакка килгәндә, без
һәрвакыт туңдырма сатып алабыз.
– Әйдәгез, – сабырсызланып кычкырам.
– Сәгать ике инде!

Безгә соңларга ярамый.
Әбәйнең килүе атна ахырының
иң күңелле чагы.

Әбәйнең килүе кыздырган
бәрәңгедән дә яхшырак.

# Бүлем 3

Икенче катта лифттан чыгабыз.
Анда телефоннар сату бүлеге.
Телефоннарга күз салам.
Алар барысы да иске һәм кызыксыз.
Әни дә телефоннарга карый,
ләкин әти миңа бага.

– Кайсын телисең? – дип сорый.
– Тегесен, – әйтәм һәм бармагым белән
зәңгәр төсле телефонны күрсәтәм.

– Тегенеме?
Ул артык бәяле, – әти кычкырып җибәрә.
– Аның батареясы бик яхшы, –
сатучы әйтә.
– Уеннары күп булсын, –
мин сатучыга әйтәм.

– Кычкырма, Филип, – әни әйтә.
– Батарея мөһим.
– Син бит бик еш телефоныңны йөкләргә
онытасың, – әти әйтеп куя.
– Менә бусында уеннар күп, –
сатучы әйтә һәм ак телефонны күрсәтә.
– Юк, без акны теләмибез.

Ул шунда ук пычрана, –
әни каршы куя.
– Төсен алмаштыра аласыз, –
сатучы әйтә.

– Мин теге яшел
телефонны телим, –
әйтәм дә, бер
телефонны күрсәтәм.
– Ул яхшыга охшый.

– Мин сиңа
шалтыратырга телим.
Миңа син кая
һәм нишлисең икән,
белергә кирәк, –
әти әйтә.

– Шуның өчен бит без
сиңа телефон алабыз, –
әни өстәп куя.
– Синдә барысы да
яхшымы, без аны
белергә тиеш.

– Яшел телефон
артык кыйммәт, –
әти сүзне тәмамлый.



# Бүлем 4

Әни сәгатенә карый.
– Сәгать хәзер өч инде! Филип, тиз генә карар кылмасаң, бүген телефон алмыйбыз, – дип каты әйтә.
– Балалар өчен модельләр бармы? – әти сорый.
– Бу кара телефонда фәнәре бар, һәм батареясы яхшы, – сатучы җавап бирә.
– Бәясе күпме? – әти борчылып сорый.
– Бу бездә иң арзаны, – сатучы җавап бирә.
– Бик уңайлы күренә, – әни әйтә.
– Ул ямьсез, – мин каршы киләм.
– Уеннары да юк.

Әни сулап ала. Әти дә сулап ала. Сатучы елмая.
– Бу телефонда ике уены бар, ләкин сез һәрвакыт күбрәк уеннар сатып ала аласыз, – сатучы әйтә.
Мин ни булса әйтергә авызымны ачам, ләкин әти әүвәлрәк өлгерә.
– Аны алабыз, – дип карар кыла.
– Юк, – кычкырып җибәрәм.
– Әйе, – ди әти.

# Бүлем 5

Мин ачуланам, чыннан да кызам.
Әти-әнием ул кара телефонны
миңа сатып алды.
Анысын яраттылар.

Минемчә, телефон ямьсез һәм дә көлке.
– Бу шәп телефон, – әти әйтә.
– Батареясы яхшы, – әни өсти.
– Булса соң, – җавап бирәм.
– Мин аны күрә дә алмыйм.

– Чыраеңны сытма.
Аны яратырсың, – әти ышандыра.
– Яратмыйм.
Мин аны беркайчан да
кулыма да алмыйм, – каты әйтәм.

Әнигә күлмәк алырга кирәк.
— Чынлап та миңа бүген яңа күлмәк
табарга кирәк, – ди.

Нигә? Һич тә аңламыйм.
Минем әле дә кәефем юк
һәм аның әйткәннәрен тыңламыйм.
Лифт безне кибетнең

бишенче катына илтә.
Әни күлмәкләр карый.
Аннары чалбар эзли.
Бик озак вакыт үтә.

– Әни, – кычкырам.
– Мин өйгә кайтырга телим.
Сәгать өчне узды инде.
Әбәй тиздән килер.
Туңдырма да алырга кирәк!

– Бераз түземле бул, Филип.
Тиздән өйгә кайтабыз, –
әти әйтә.
– Минем бер күлмәк карарга да
хәлем калмады, – кычкырам.

– Син теләгәнчә, – әни әйтә.
– Менә монда
эскәмиягә утыр.
Беркая да китмә.
Без тиздән кайтырбыз.

Мин эскәмиягә утырам.
Кызыксыз.
Нишлим соң?

# Бүлем 6

Яңа телефонымны
кулыма алам да карыйм.
Әйләндереп багам.

Телефон кечкенә һәм җиңел,
кулда шома тоела.
Гади көйләр генә уйнатып була
һәм ике көлке уены гына бар.

Әни белән әти күренми.
Телефонда уйный башлыйм,
башка эшем юк.

Бер уенында космостагы җан ияләре.
Аларны атып төшерәм.
Бум! Бум!

Телефон шалтырый. Әти шалтырата.
– Сәлам, Филип, – әти әйтә.
– Хәлләр ничек?
– Сез кайда? – сорыйм.
– Кайчан өйгә кайтабыз?
– Туңдырма алабыз, – әти әйтә.
– Без ризык кибетендә.
Бу беренче катта.

Монда килергә телисеңме?
– Юк, рәхмәт, – җавап бирәм.
– Мин сезне монда көтәм.
Миңа лакрица алыгыз.

– Без сине тиздән килеп алабыз, –
әти әйтә.
– Тизрәк булыгыз, –
кычкырам.
– Сәгать өчне егерме
минут узган инде.



Элемтә өзелә.
Тагын да уенны ачам.
Телефонның бер яхшы
үзенчәлеге бар.
Аның исеме Дәвам ит.

Димәк, кем булса
миңа шалтыратса,
уенны һаман да
яңадан башларга
кирәкми!
Бүленгән җирдән
дәвам итә алам.

Мин уйныйм.
Бум! Бум!

# Бүлем 7

Телефон тагын шалтырый.
– Филип, хәл ничек? – әти сорый.
– Уенымны боздың, – әйтәм.
– Ашыйсым да килә.
– Туңдырманы алдык, – әти әйтә.
– Кибеттә озак көтәргә туры килде.
Һәрьякта халык бик күп.

– Сез кайда? – сорыйм.
– Лифтны көтәбез,– әти әйтә.
– Ләкин ул бөтен вакыт мәшгуль.
Син аска, беренче катка, йөгереп килә
аласыңмы? Яки автоны таба аласыңмы?
– Әлбәттә, автоны табам, – җавап бирәм.
– Лифтка менеп, Б катына төш.
Аннары сулга борыл, – әти аңлата.
– Таба алырсың бит?
– Әлбәттә, – җавап бирәм.
– Без сине авто янында көтәрбез, –
ди әти һәм сүзен тәмамлый.
Мин лифтка йөгерәм.
Сәгать дүртенче ярты. Әбәй ярты
сәгатьтән килә. Кибеттән өйгә
кайтырга егерме минут үтә.
Әле өйгә вакытында өлгерәбез.

# Бүлем 8

Лифт төймәсенә басам.
Лифт килгәнче
ике тулы минут үтә.

Лифт халык белән тулган.
Көчкә-көчкә арага сыям.
Кысылып керәм дә,
бер абыйга бәрелеп алам.

– Ай, – абый кычкырып ала.
– Алдыңа кара!
– Ой, – мыгырданам. – Гафу итегез!
Бер адым артка таба алам да,
бер апаның аягын таптыйм.
– Ай, – апа кычкырып җибәрә.
– Нишлисең?
– Гафу итегез, – мин тагын мыгырданам.

Өметсез. Кузгала да алмыйм,
һаман кем булса юлымда.

Б төймәсенә басам.
Абый А төймәсенә баса.
Лифт кузгалып китә.
Ул өскә менә!

Лифт алтынчы катта туктый.
Аннары аска төшә һәм
дүртенче катта туктый.
Тагын өскә, бишенче катка менә.
Нигә лифт мин теләгән урынга бармый?

Б төймәсенә тагын басам. Шәп!
Әле аска таба төшәбез.

Лифт икенче катта туктый һәм
аннан соң беренче катта.
Халыкның күбесе лифттан чыга.

А катында абый белән апа чыгалар да,
мин ялгыз калам.
Лифт төймәсенә озак басып торам.
‒ Б катына төш!
Хәзер! Шунда ук, ‒ лифтка кычкырам.

Лифт Б катына әкрен генә төшә.
Сәгатькә карыйм.
Йегерме ике минут калган.
Аз калды, соңламадым.
Өйгә вакытында кайтып өлгерәбез.
Лифт Б катында туктый.

Эшем уңды!

# Бүлем 9

Лифттан чыгам.
Бу катта байтак кына караңгы.
Сулга барам, ләкин безнең
автобызны таба алмыйм.
Берсе дә безнең автога охшамаган.

Анда кара БМW, кызыл Вольво
һәм иске Тойота тора.
Ачык яшел автолар юк,
Опель дә юк.
Уңга борылам.
Анда да ачык яшел авто юк.
Бу Б каты була алмый.
Лифтта ялгыш төймәгә басканмын.
Сәгатькә карыйм.
Йегерме минут калган.
Әтигә шалтыратырга кирәк.

Телефонымны кесәдән чыгарам.
Телефон эшләми. Яраксыз әйбер!
Аны кире кесәмә салам.
Әле уйларга кирәк, аңладым,
дөрес катта түгелмен.
Димәк, миңа лифтка кире
кайтырга кирәк.

Ярты минуттан соң лифт алдына килеп
басам.Төймәгә ничә тапкыр басам.
Көтәм, ләкин лифт килми.
Тагын сәгатькә карыйм.
Унҗиде минут калган.

Лифт янында баскыч бар.
Бәлки дә өстәге катка җәяү менәләм.
Ул ахрысы Б каты.

Баскычка керә торган ишекне ачам да,
шунда лифт тавышын ишетәм.
‒ Пим! ‒ лифт тавышлый.
Ишекләре ачыла.

Борылам да йөгерәм,
ләкин вакытында өлгермим.
Ишекләре ябыла.
Лифт тагын пим дия дә, өскә китә.

Лифтне чакырыр өчен
төймәгә баскалыйм.
Лифт туктамый.
‒ Яраксыз әйбер! ‒ баскычка кайтам да,
ишекне тартып ачам.
Баскычтан өскә йөгереп менәм.
Уналты минуттан әзрәк вакыт калды.

# Бүлем 10

Бу катның ишегендә зур А хәрефе.
Сул якка карыйм.
Анда ачык яшел авто тора.
Кемдер авто янында баскан.
– Әти, – кычкырам.
– Ялгыштың! Бу А каты.

Ләкин... ул әти түгел.
Ул мин танымаган абый.
Әтидән олырак һәм чәче ак.

Кычкырганымнан оялам.
– Гафу итегез, – әйтәм.
– Сез минем әтием дип уйладым.
– Әтиең кайда көтә? – абый сорый.

Ой, юк! Бу чын була алмый.
Бу мин лифтта бәрелгән абый.

– Б катында, – әйтәм.
– Мин астагы катта идем.
Ул анда юк иде.
– Бу дөрес кат дип уйлысыңмы, –
абый сорый.
– Биредә А, Б, Д һәм П катлары бар.

Д яки П булырга мөмкинме?
– Әти Б каты дип әйтте, – җавап бирәм.
– Бәлки дә ул ялгышкандыр.

– Беренче катта лифт янында
карта, харита бар, –
абый йомшак кына әйтә.
– Аны күрдеңме?
– Юк, – җавап бирәм.
– Һаман хариталарны карарга кирәк, –
абый әйтә. – Онытма.
Алай юлыңнан адашмыйсың.
Әтиеңә шалтыраттыңмы?
– Әлбәттә, ләкин телефоным эшләми, –
җавап бирәм.

Абый үз телефонына карый.
Башын чайкый да әйтә:
– Минеке дә эшләми.
– Нигә эшләми? – сорыйм.
– Телефон челтәрен таба алмый, –
абый әйтә. – Без җир астында.
Җир астында челтәр юк.
Биредә шалтыратуның файдасы юк.
Әтиең дә, бәлки, кайдадыр
челтәр булмаган катта.

Кемдер авто эчендә тәрәзә шакый.

# Бүлем 11

– Тиздән китәбезме инде? –
Автодан ачулы тавыш кычкыра.
 – Әйе, шунда ук китәбез, –
абый җавап бирә.

– Кем белән сөйләшәсең? –
тагын сорый.
– Бер малай белән,
әтисен югалткан, –
абый җавап бирә.

Шунда автодан бер апа карый.

Лифтта бу апаның аягына
баскан идем.

– Әһә, – апа әйтә.
– Бу малайны беләм бит.

Харап булдым!
Тиз генә баскычка йөгерәм.

Унике минут калган.

# Бүлем 12

Киләсе катның ишеге
бераз ачык.
Аны ачам да,
тиз генә кереп китәм.
Минем артта ишек ябыла.
Дөм караңгыда калам.

Бу кат та
дөрес түгел, күрәсең.
Монда һич автолар юк,
кешеләр дә юк.

Караңгылык кына.
Кая килдем?

Баскычка кире кайтырга кирәк.
Ничек? Берни дә күрмим бит.

Кулларымны сузам да,
әкрен генә борылам.
Капшана-капшана алга таба барам.

Тегендә ишек.
Тоткасы кая? Тегендә!
Аны басам.

Селкенми дә.
Тагын басам да,
җилкәм белән ишекне төртәм.
Ишек кузгалмый.

Бәлки дә тотканы басып
берьюлы ачарга кирәк?

Бармакларым белән биген эзлим.
Бикне табам,
ләкин ача алмыйм.
Ачкыч кирәк.

Кулымны кесәгә тыгам.
Өй ачкычым белән ачып карыйм,
ләкин ул биккә туры килми.

Ә, велосипед ачкычы?
Ул да биккә туры килми.
Бигрәк кечкенә.

Ишекне тагын төртәм,
ләкин ул кузгалмый да.

Ачуым килә.

# Бүлем 13

Ишеккә акырам. Аяк белән тибәм дә,
кулларым белән кагам.
– Ачыл! Моннан чыгарга телим, –
кычкырам.
Ишек урыныннан кузгалмый.
Ишеккә аркам белән таянам.
Бик арганымны сизәм

– Уйла! Әйбәт кенә уйла, –
үз-үземә әйтәм.
– Моннан ничек чыгарга?
Ләкин уйларга хәлем юк.
Баш мием тәмам каткан,
эшләүдән баш тарта.

Уйла... уйла, әгәр дә
биредән беркайчан да чыгалмасам?
Минем монда булуымны
беркем белми бит. Ачлыктан үләрмен.
Ризык турында уйлана башлыйм.
Кыздырган бәрәңге ашыйм
дип күз алдыма китерәм.
Юк! Ризык турында уйларга ярамый.
Аның турында уйлагач,
күбрәк кенә ачыгам.

– Әни белән әти мине эзлиләр.
Алар мине тиздән табарлар.
Бик тиз табарлар, үз-үземә сөйләнәм.

Аннары үземне бераз кыюрак хис итәм.
Әтигә шалтыратырга тырышам.
Моннан шалтыратып буладыр.
Әле мин җир өстендә булырга тиеш.

Телефонымны чыгарам.
Экраны ачык яшел.
Караңгыда кечкенә
өрәк кебек ялт-йолт итә.
Телефоным челтәрне тапмый.
Мин һаман да җир астында.
Әтигә шалтырата алмыйм.
Кыскасы, беркемгә дә шалтырата алмыйм.

Мин көтәләм генә.
Әни белән әти мине тапканга кадәр
монда гына тора алам.
Яисә бу караңгылыкка
кем дә булса башка керә дә, мине таба.
Кем булса да, тиз генә килсен инде.
Кем генә.
Кулларым калтырый.
Өч минут калган. Тиздән сәгать дүрт.
Әбәй ни әйтер?

# Бүлем 14

Телефон экраны кинәт сүнә.
Куркынам.
Караңгылык куркыта.
Телефонның экраны кабынганда
караңгылык андый куркыныч түгел.

Телефон төймәләренә басам.
Искәрмәстән фәнәр кабына.
Фәнәре бар икәнне онытканмын.
Шатланам.

Телефонның фәнәре зур түгел.
Ул салкын ак ут тарата.
Аның уты дөм караңгылыкта
кечкенә бер түгәрәк кенә.
Ут миңа җитә.
Тирә-ягымны күрә алам.

Бармагымны төймәдән
күтәрәм дә,
фәнәр сүнә.
Тагын кабызам.

Бармагымны төймәдә
тотып торырга кирәк.

Тотмасам, фәнәр сүнә.
Фәнәр белән ишекне яктыртам да,
биген тикшерәм.
Тоткасын һәм бөтен
ишекне тикшереп чыгам.

Ишекне ачып булмый.
Мин ялгыш ягында.
Миңа тышкы якта баскычта
булырга кирәк иде.

Бер үк вакытта куркам да,
ачуланам да.
Елыйсым килә.
– Мине җибәр! – кычкырам.

Ишекне кагам.
Фәнәр сүнә.

Телефоным кая китте?
Кулымнан ычкынды.

Аягым белән
телефонны эзлим.
Кулым белән табарга тырышам.

Кая югалды?

# Бүлем 15

Кинәт кулым ниндидер каты әйбергә тия.
Нинди бәхет! Телефон.
Телефонны җирдән күтәрәм дә,
нык кына кулымда тотам.
Аны тагын югалтырга ярамый.

Һәрхәлдә телефон яхшы.
Ул караңгылыкта минем дустым.
Чыннан да шәп телефон.
Мин аны яратам.
Нәкъ шул вакытта сөйләү һәм
аяк тавышлары ишетәм.
Кемдер тышкы якта
болдырдан узып бара.
Ишекне даңгырдатам.
Кычкырам һәм дә тибәм.

– Ярдәм! Ярдәм! Мин бикләндем.
Мине чыгарыгыз, – кычкырам.
Ләкин сөйләү һәм адым тавышлары югала.
Тагын тып-тын була.
Сулыш алганымны үзем ишетәм.
Караңгылыкта яңгырый.
Аякларым да кулларым авырта.
Ишеккә артык каты сукканмын.

Битемдә күз яшьләре тәгәри.
– Әни, әти!
Мин өйгә кайтырга телим, – кычкырам.
Озак вакыт елыйм. Аның файдасы булды.
Елагач, үземне рәхәтрәк хис итәм.

Кинәттән сизәм.
Битемне җил сыйпап ала.
Ой! Ул бер нәрсәне генә белгертә.
Кайда булса тишек, яки ишек,
яки тәрәзә бар.

Күз яшьләремне киптерәм.
Миңа анда барырга кирәк.
Миңа җил өрә торган
урынны табарга кирәк.

Чыгу анда. Әлбәттә.
Миңа куркырга кирәкми.
Шулай да бик каты куркам.
Караңгыда әллә нәрсә
яшеренгән булырга мөмкин.

Алай булса да, кузгалам.
Анда барырга кирәк.
Тышка чыгар өчен
юлны табарга кирәк.
Монда калырга теләмим.

# Бүлем 16

Аягым белән сакланып кына
идәнне капшыйм.
Идән кытыршы һәм таштан ясалган.
Берничә адым атлыйм.

Фәнәр белән диварны яктыртам.
Ул шулай ук таштан ясалган.
Тагын берничә адым атлыйм.

Икенче якта да дивар бар.
Алдарак караңгылык кына.
Әле аңлыйм. Мин туннельдә.

Фәнәр белән алны яктыртам.
Ут нәрсәгәдер тиеп ала.

Туннельдә күләгә күренә.
Күләгәнең кулы бар.
Кулында чүкеч.

Күләгә әкрен генә миңа таба килә.
Мин артка, ишеккә таба йөгерәм.

Кычкырам:
– Ярдәм! Ярдәм!

# Бүлем 17

Кычкырган тавыш туннельдә яңгырый.
Мин абынам да, егылып китәм.
Идәнгә йөзтүбән ятам.

Башымны саклар өчен
кулларымны башыма куям.

Кузгалырга куркам һәм
куркуымнан тын да ала алмыйм.
Берничә секундтан соң
үләм дип беләм.
Җанвар мине үтерә.

Тып-тын. Шыпырт та юк.
Ашыккан аяк тавышлары да ишетелми.
Җанвар да юк.

Бераз урынымда торам.
Тагын тын ала алам.
Сакланып кына башымны күтәрәм.
Тирә-ягым әле дә тып-тын.

Әкрен генә торам да,
тирә-ягымны күзәтәм.
Фәнәр белән туннельне яктыртам.

Җанвар урынында тора.
Җанварның кулында
хәзер дә чүкеч.

Якынлашам һәм
җанварга карыйм.
Ул кечкенә җир казу машинасы гына икән!
Машинаның чүмече бар.
Мин чүмечне
зур чүкеч дип уйладым.

Үземә ачуланам.
Нигә мин бер казу
машинасыннан курыктым?

Мәктәп дусларым белсәләр,
миннән көләрләр иде.
Мин аларга беркайчан да
бернәрсә дә әйтмим.
Туннельдәге җир казу машинасын
телгә дә алмыйм.

Машина янына барам.
Казу машинасы кечкенә,
сары һәм тузанлы.
Тотынып карыйм.
Бармакларымнан тузанда
эзләр кала.

Тузанлы ян тәрәзәсенә
елмая торган бит ясыйм.

Менә болай!
Әле казу машинасы
матуррак күренә.

Туннельдә утны алгарак яктыртам.
Тагын машиналар бар микән?

Юк. Туннель буш.
Җилне тагын сизәм.

Берничә адым алга атлыйм.
Тагын да күбрәк җилләтә һәм
аш исе борынга бәрелә.

Кыздырган бәрәңге!
Шунда ук бик каты ашыйсым килә.

Искә таба барам.
Аш исе көчәя генә бара.

Кинәт адымнар һәм
сөйләү тавышлары ишетәм.

# Бүлем 18

Яңгыраткыч тавышын ишетәм.
Ул кибетнең яңгыраткычы.

Фәнәрем белән диварга карыйм.
Анда соры таштан башка нәрсә юк.

Ут белән түшәмне яктыртам.
Анда бер тишек бар.
Тишекне ятьмә каплаган.
Ул тишек һава алмаштыру өчен.
Җилләтү тишеге.

Кибетнең һавасы туннелгә төшә.
Туннелдән саф һава
бинага китә.

– Филип, Филип, –
яңгыраткыч кычкыра.
– Филип инфобюрога кил.
Әни белән әти сине көтәләр.
Филип, Филип, инфобюрога кил.
Әни белән әти сине көтәләр.
– Киләм, – кычкырам.
– Ләкин ничек?
Әйтегез, инфоны ничек табыйм!

Мин фильмнарда күп мондый
җилләтү тишекләре күргәнем бар.
Фильмнарда барысы да бик җиңел.
Анда каһарман дивар буйлап
үрмәкүч яки кәлтә кебек менә.

Ятьмәне ала да,
җилләтү тишегенә кысылып керә.
Аннары каһарман беренче катка менә.

Анда инфобюро.
Анда әни белән әти көтәләр.

Ләкин бу фильм түгел һәм дә
мин каһарман түгелмен.
Шома диварга менә алмыйм.

Мин, мин генә, Филип,
һәм дә теге кечкенә
тишеккә сыймыйм.

Бер нәрсә эшли алам:
җилләтү тишегеннән кычкыра алам.
Кем булса мине ишетер.

Аяк бармакларыма басам.
Җилләтү тишегенә
җитәргә тырышам.

– Ярдәм! – мөмкин кадәр
каты кычкырам.

Бер мизгел көтеп торам.
Аннары бер тапкыр
тагын тырышам, катырак:
– МИН МОНДА.
Филип туннельдә!

Аш исе бәрелә.
Тавышлар шаулый.
Яңгыраткыч Филип
дип тагын кычкыра.

– Мин монда, – акырам. –
Туннельдә!
Туннельдә!

Мин аларны ишетәм,
ләкин мине беркем
дә ишетми.

Кибеттә бик күп тавыш.
Туннельдә мин берүзем.

Әле нишлим?



# Бүлем 19

Миңа алга таба барырга кирәк,
болай тилерәм.
Монда кала алмыйм.

Әни белән әти инфо янында көтәләр.
Озакламый полициягә шалтыратырлар.
Аннары алар мине
эзли башларлар.

Әле миңа нык кына
уйларга кирәк.
Кире ишеккә кайтыйммы?

Юк, аның ярдәме юк.
Алар мине анда эзләмиләр.
Алар мине кибет эчендә эзлиләр.
Беркем минем туннельдә булганымны
күз алдына да китерә алмый.

Алга таба китәргәме икән әллә?
Бәлки дә.

Туннельгә керү бар,
чыгу да булырга тиеш.
Барлык туннельләрдә керү дә

чыгу да бар.
Алга таба барырга карар кылам.
Туннельдә тагын да
эчкәрәк керәм.
Чыгу юлын табарга кирәк.
Аннары инфога барам да,
берни булмаганга салышам.

Әнигә дә әтигә
бераз йөрдем генә
дип әйтермен.
Туннель турында чынбарлыкны
әбәйгә генә аңлатырмын.

Туннельдә әкрен генә
эчкәрәк барам.

Көт. Тукта.
Тегендә әллә нәрсә кыймылдана.
Фәнәр белән анда
таба яктыртам.
Юк, югалды.
Тагын ул анда, уң якта.

Фәнәр белән аны эзлим.
Әнә, тегендә!
Нәрсә булырга мөмкин?

# Бүлем 20

Күсе. Бик зур күсе.
Дөнья кадәре зур, коточкыч күсе!

Күсе миңа карый.
Мин күсегә карыйм.
Аңа тотына алам диярлек.
Күзләре кара һәм
койрыгы озын.

Калтыранам.
Күселәр тешлиләр һәм алар куркыныч.
Алар кеше ашыйлар дип укыганым бар.
Бер күсе бербөтен
кешене ашый ала.

– Кит моннан! – кычкырам,
ләкин күсе кузгалмый.
Ул миңа бераз вакыт карап тора.
Аннары үз юлына китә.
Мин фәнәр тотып аның артыннан барам.

Кинәт күсе борыла да,
миңа таба йөгерә.
Юк, ул башка күсе.
Күселәр монда хисапсыз күп!

Кычкырам һәм дә биеккә сикерәм.
Күсе куркына,
дивар буйлап качып китә.

Җирәнгеч хайван!
Йөрәгем котырынып тибә һәм
бөтен тәнем калтырый.

Мин бит күселәрне таптый ала идем.
Берсе мине тешли алган булыр иде.
Тагын тетрәнәм.

Тирә-ягымны фәнәр белән яктыртам.
Күселәр күбрәк күренми.
Тагын нормальчә тын ала башлыйм.

Фәнәр сүнә һәм мин аны кабызам.
Сәгатькә карыйм.
Тиздән бишенче ярты.

Бик соңга калдым инде.
Әбәй пошынадыр.
Туңдырма күптән эрегәндер инде.
Чыгу юлын табарга кирәк.
Юлымны дәвам итәм.

Лач!

# Бүлем 21

Бер аягым белән суга басам.
Аягым шуннан ук юешләнә.
Күлләвектә басып калам.

Күлләвекнең икенче ягына сикерәм.
Күлләвек зур түгел.
Суы каян килә икән?
Фәнәрем белән идәнне яктыртам,
әмма лампа сүнә.

Тагын кабызам.
Уты көчсез.
Телефонның батареясы буш диярлек.

Инде мин ахмак!
Батареясын уйнап бушаттым.
Нигә шундый күп уйныйм икән?
Бәлки дә батареясы
бөтенләй йөкләнмәгән иде.

Әле миңа телефон да,
батарея да кирәк.
‒ Моннан соң телефонда уйнамыйм.
Үземә һәм бөтен дөньяга сүз бирәм! ‒
дип кычкырып әйтәм.

Тавышым туннельдә яңгырый.
– Телефон, телефон,
туннель җавап кайтара.
Диварларны яктыртам.
Алар бик юеш.

Түбәдән су тама да,
дивар буйлап ага.
Аннары ут сүнә.

Мин аны кабат кабыза алмыйм.
Туннель тагын да бик
куркыныч булып тоела.

Караңгыда әкрен басып торам.
Берни күрмим.
Су тамганны гына ишетәм.
Шаулау тавышы да ишетәм.

Нинди шау-шу? Бераз көт.
Кешеләр шаулыйлар.
Туннельдә кешеләр булырга тиеш.

Тавыш ерактан
туннель эченнән килә.
Бара башлыйм.
Чәпелт итеп тагын да суга басам.
Уң якка сикерәм.

Анда коры.
Кулым белән диварга тотынам.
Тагын өч адым атлыйм.

Шак! Ай!
Диварга башымны сугам да,
кинәт йолдызлар күрәм.

Баш авырта,
маңгаемда шеш һәм тырналган урын.
Бармакларымда
кан бар икәнен тоям.

Туннель монда бетә һәм
чыгу юлы юк.
Ялгышканмын.

Тавыш, әлбәттә,
һава тишегеннән килә.

Тукта... Нинди тавыш бу?
Тагын тавыш ишетәм.

Туннель дәвам итә һәм
алдарак кешеләр бар.

Аннары сизәм,
телефонымны югалтканмын.

# Бүлем 22

Ике адым артка атлыйм да,
бармакларым белән җирне капшыйм.
Кулым ниндидер йомшак нәрсәгә тия.

Күсе! Телефоным кайда булса булсын.
Калтыранам.
Күсенең тешләгәнен теләмим.

Кулымны сузам да, диварга кагылам.
Дивар бетә.
Аһ! Туннель борыла.
Әгәр диварга тотынып барсам,
юлны табармын.
Туннельнең борылганын да аңлармын.

Сакланып кына алга барам.
Колак тирәмдә җил исә.
Тагын тавыш ишетәм. Байтак якында.
Тавышлар ишетәм. Анда кешеләр бар!
Диварны тотарга онытам.
Тавышка таба йөгерә башлыйм.
Әле тавышлар ачык ишетелә.

Ялт итте!
Көчле ак ут күземә бәрелде.

# Бүлем 23

Диварга сыланам.
Дивар аркамны тырный.
Кузгалырга куркам.

Күзләремне бер йомам,
бер ачам.
Күзләрем яктылыкка күнә башлый.

Алдымда бер генә дивар бар.
Диварга ут бәрелә.
Һавада тузан әйләнә.
Зур ак машина тавыш чыгара.
Тузан эчендә сәер
җан ияләре кыймылдыйлар.

Җанварлар гигантлар кебек зур һәм
көмеш киемнәр киеп йөриләр.
Башлары зур, түгәрәк һәм
куллары да бик зур.
Аякларында зур кара итекләр.

Болар кешеләр түгел.
Кешеләргә охшамыйлар.
Болар тышкы галәм җанварлары
булырга кирәк.

Роботлар.
Әйе, алар робот булырга тиеш.
Аларны фильмда күргәнем бар.
Роботлар куркыныч.
Алар кешеләрне күрә алмыйлар.

Бу роботлар кибет астында
туннель казыйлар.

Озакламый, кем дә көтмәгәндә,
алар җирдән чыгарлар.

Туннельдә роботлар булганны
кешеләр белмиләр бит.
Артык соң булганчы,
кешеләрне кисәтергә кирәк,

Чыгу юлын да табарга кирәк.
Роботлар кибеткә кергәннән
әүвәл миңа өлгерергә кирәк.

Тәмам шул вакытта машина
тагын тавыш чыгара.
Чүмече белән ташлар
һәм чүпләр күтәрә дә,
өстемә ташлый.

Мине күргәннәр!

# Бүлем 24

Урынымнан бераз күчәм дә,
читкә ташланам.
Янымда чүп-чар җиргә төшә.

Туннельгә эчкәрәк
йөгерергә тырышам.
Абынам һәм егылам.
Чүмеч миңа тия диярлек.
– Саклан, – роботларның
берсе кычкыра.

Өстемә тузан куна.
Йөткерәм.
Идәнгә сузылып ятам.
Машина чүмече
өстемдә эленеп тора.

Чүмеч күтәрелә дә,
машина туктый.
Роботларның берсе
яктырткыч лампасының
утын миңа төби.

Ак уттан башка бернәрсә
дә күрмим.

Кулым белән
күзләремне каплыйм.
– Син монда нишлисең? –
робот ачуланып сорый.
Беләгемнән тота да,
аягүрә торгыза.
Җилкәләремнән тота да,
мине селки башлый.

– Син монда ничек килдең? –
дип кискен сорый робот.
Авызым коп-коры.
Авызымнан өн дә чыкмый.

– Ишектәге күрсәткечне
күрмәдеңме?
Монда керергә ярамый, –
робот кычкыра.
Мине тагын тотып селки.

– Яктырткычны башка якка бор.
Малай берни күрми бит, –
башкасы әйтә.
Бу роботның тавышы йомшак.

Утны диварга төбиләр.
Хәзер мин роботларны
якыннан күрәм.

Алар өчәү.
– Юлыңнан адаштыңмы? –
ягымлы робот сорый.

Роботлар ягымлы түгел.
Бу робот яхшыга
салыша гына.

– Сөйләшә
белмисеңме? –
усалрагы сорый.
Ул мине тагын тотып
селки башлый.

Икенчесе аны бүлә.
– Тукта, – ягымлы
робот әйтә.
– Күрмисеңме, малай
бөтенләй куркынган?

Робот башлыгын сала.



# Бүлем 25

Робот ‒ кеше.

Ул каскасын кулында тота.
Бу ир акыллыга охшаган.
Чәче тузган.

Ир миңа елмая.
‒ Минем исемем Рауф, ‒ әйтә.
‒ Сәлам!

Эш бияләен сала да,
кулын суза.
Мин дә аңа кулымны бирәм.
‒ Сиңа куркырга кирәкми.
Без куркыныч түгел, ‒ Рауф әйтә.

Минем борыным тузан белән тулган,
төчкереп җибәрәм.
‒ Саулыкка, ‒ Рауф әйтә.
‒ Рәхмәт, ‒ пышылдап әйтәм.

Сөйли алмыйм диярлек.
Тамак тузаннан кипкән.
Тын ала алганчы
бераз йөткереп алам.

– Исемең ничек? – Рауф сорый.
– Филип, – пышылдыйм.
– Син монда ничек эләктең?
Үзеңне җәрәхәтләгәнсең, –
Рауф әйтә дә,
маңгаемдагы тырналган
эзне күрсәтә.

– Ишек ачык иде, –
мин кысылган тавыш
белән әйтәм.
Тагын төчкерәм.
– Бер минут, – Рауф әйтә.

Кесәсендә казына.
Бер пакет кулъяулыклар таба.
Миңа бер кулъяулык суза.
Аннары усал роботка борыла.

– Кәрим, ишетәсеңме,
тагын илтифатсыз булгансың.
Ишекне ябарга онытк ансың, –
Рауф әйтә.

Кәрим каскасын сала.
Ул әле дә ачулы булса да,
сөйкемле булып күренә.

– Әйе, әйе, – Кәрим әйтә.
– Барысын да хәтерли алмыйм.
Ләкин син монда,
чынлап та,
ничек килеп җиттең?
Юл караңгы бит.
Күселәр дә бар.

Мин елмаям да,
иңбашларымны сикертәм.



# Бүлем 26

Өченче робот казу машинасының
эчендә утыра.
Ул миңа кул селки.
– Бу Соня, – Рауф әйтә.

Мин дә Соняга кул селким.
Ул машинадан чыга да,
миңа кул бирә.

– Сәлам сиңа, – Соня әйтә.
– Маҗаралар эзләргә чыктыңмы?

Рауф кашларын җыерып,
миңа карый.
Ул уйлый.

– Безгә синең белән
нишләргә икән? – сорый.
– Безнең белән монда
калырга телисеңме?
Тиздән эш көнебез бетә.
Көтә аласың.
Яисә теләбрәк
кибеткә кайтасыңмы?
– Кибеткә, – җавап бирәм.

– Әни белән әти мине
инфобюрода көтәләр.

– Әһә, – Рауф әйтә дә, тагын уйлый.
– Бусы бераз кыенрак.
– Нигә? – исем китә.

– Нинди булса фәнәрең бармы? –
Рауф сорый.
– Минем фәнәрем ватык.
Кәрим үзенекен югалткан.
Әлбәттә, күселәр
аны ашап куйган.
– Юкны сөйләмә, –
Кәрим әйтә.

– Мин телефонымны
туннельдә югалттым, – әйтәм.
– Телефонның фәнәре бар,
ләкин батареясы бетте.

– Минем фәнәремне алыгыз, –
Соня әйтә.
Ул бик шәп ут бирә.
Миңа зур гына фәнәр суза.

– Рәхмәт, син искиткеч, –
Рауф әйтә.

– Алайса әйдә, Филип.
Туннельдә Рауф минем
алдымда бара.
Ул озын адымнар белән атлый.
Артыннан өлгерер өчен
миңа йөгерергә кирәк.

Ул монда
ничә тапкыр йөргән,
аягын кая куярга белә.

Кинәт туктый.

– Карачы, – Рауф әйтә.
– Тегендә әллә нәрсә
ялт-йолт итә.
Синең телефоныңмы?

Телефоным җирдә,
экраны өскә бага.
Аның янында
башка нәрсә дә бар.

Фу, бик җирәнгеч!

# Бүлем 27

– Ул минем телефоным, – Рауфка әйтәм.
– Ләкин аның янында
үлгән күсе.
Рауф фәнәрен күсегә төби.
Кычкырып көлә.

– Бу күсе түгел, – ыржаеп әйтә.
– Ул Кәримнең башлыгы.
Ул кичә аны югалткан иде.
Шәп, син аны таптың.
Кәрим шатланыр.

Рауф башлыкны җирдән күтәрә.
Аны кага да сөртеп ала.
аннары кесәсенә сала.

Мин телефонымны күтәрәм дә,
аны җентекләп карап чыгам.
Ватылмаганга охшый.
Телефонымны кесәгә салам.

– Күселәр кешегә куркыныч түгел, –
Рауф әйтә.
– Кеше ашамыйлармы? –
минем исем китә.

Рауф тәмле генә көлә.
– Алар сөйкемсез,
ләкин куркыныч түгел, –
дип аңлата.
– Сине күргәч, качып китәләр.
Алар күбесенчә калган ризык ашыйлар.

– Ләкин мин бер күсе күрдем,
миннән курыкмады, – каршы әйтәм.

– Синең фәнәреңне күргәч,
әлбәттә, ул куркынды, –
Рауф әйтә.
– Ләкин теге нәрсә? –
Рауф су җыелган урынны күрсәтә.

– Су каян килә? – сорый.
Фәнәре белән түшәмне яктырта.
Аннары утны диварлар
һәм идән буйлап йөртә.
– Ой, – Рауф әйтә.
– Бер торбадан су тама.

Тагын түшәмгә карый.
Бөтен түшәм
торбалар белән тулы.
Кайберләре калын,
кайберләре нәзек.

Бер калын торбадан су тамып тора.

– Филип, ишетәсеңме, – Рауф әйтә.
– Моны Кәрим белән
Соняга әйтергә кирәк.
Тама торган
урынны шунда ук төзәтергә кирәк.
Әйдә!

– Мин монда
күтә алам, –
җавап бирәм.
– Чыннан дамы? –
Рауф сорый.
– Чыннан да, –
җавап бирәм.



# Бүлем 28

Рауф фәнәр белән үз юлына китә.
Тирә-ягымда караңгы була.

Мин инде курыкмыйм.
Караңгылыктан да, күселәрдән дә
курыкмыйм.
Су тама.

Рауф Соня белән
Кәримгә кычкыра, ишетәм.
Аларның адымнары якыная.
Тиздән тагын ут күрәм.

Соня яктырткыч лампаны алып килә.
– Тегеннән су ага, –
Рауф күрсәтә.
– Бәхетебезгә аны
вакытында күрдек.
Торба ярылырга тора.
Ул озак чыдамый инде.

– Аны төзәтәбез, –
Кәрим тыныч кына әйтә.

Баскыч куя да, менә.

Соня лампаны суза.
‒ Бәхетебезгә Филип
адашкан, ‒ Рауф әйтә.
‒ Болай без кичкә кадәр су
тама торган урынны
сизмәгән булыр идек.

‒ Су баскан булыр иде, ‒
Соня әйтә.

‒ Кәрим, беләсеңме нәрсә? ‒
Рауф дәвам итә.
‒ Филип синең башлыгыңны тапты.

‒ Филипкә медаль бирергә
тиеш булыр иде, ‒ Соня көлә.
‒ Нигә соң, ‒ Кәримнең исе китә.
‒ Адашканы өченме?

Кәрим көлеп баскыч башыннан
миңа карый.

‒ Филип, ишетәсеңме, ‒
Кәрим әйтә.
‒ Сиңа ике алтын медаль
бирергә кирәк.
Син адашу остасы
һәм дә табу остасы!

# Бүлем 29

Без Рауф белән икәү
туннельдән чыгабыз.
Кинәт яктырып китә.
Кешеләр сөйләшәләр һәм шаулашалар.
Кибет әле дә кешеләр белән тулы.
Рауф минем белән кибеткә керә.

Туннель чыннан да озын түгел.
Ләкин мин берүзем булганда,
бик озын тоелды.
Рауф белән барганда
кыска булып тоелды.

Кибеткә кергәч,
кешеләр безгә карыйлар.

‒ Кешеләргә исең китмәсен, ‒ Рауф әйтә.
‒ Бәлки алар беркайчан да безнең
кебекләрне күрмәгәннәрдер, ‒ әйтәм.
‒ Без ерак галәмнән яки
җир астыннан килгән
җан ияләренә охшыйбыздыр.

Рауф көлә. Мин Рауфка карыйм.
Чыннан да. Көмеш киеме белән

Рауф роботка охшый.
Итекләре зур, үзе тузанлы һәм пычрак.
Чәче һәрьякка таралган.
– Син роботка охшыйсың, – әйтәм.
Рауф тагын кычкырып көлә.
– Үзеңә кара, – әйтә.
– Кытайга кадәр туннель казыгансың
дип уйларга мөмкин!

Мин үземне көзгедән карыйм.
Мин дә бик пычрак.
Маңгаемда тырналган эз һәм шеш.
Чәчемдә гөрмәкчә ятьмәсе.
Киемем пычрактан каралган һәм
башмакларым тузаннан соп-соры булган.

– Инфо тегендә, – Рауф әйтә.
– Инфо янында ике кеше баскан,
әти-әниеңдер?

Рауф бармагы белән әти-әнигә күрсәтә.
Алар инфо янында басканнар һәм
алар тирәсендә берничә кибет
сакчысы да бар.
Әни белән әти сакчылар
белән сөйләшәләр.
Минем исememне әйтәләр, ишетәм.
– Әни, әти, – мин кычкырам.

# Бүлем 30

Әни белән әти янына йөгерәм.
Йөгергәндә әбәй дә
анда икәнен күрәм.
– Әбәй, – кычкырам.
– Филип, – әни кычкыра.
– Без бик борчылдык!

Әни мине каты гына кочаклый.
Аның күзләре кызарган.
Елаганга охшый.
– Филип, – әти кычкыра.
– Ниһаять! Ул да мине кочаклый.
Йөзе ап-ак.

Әбәй бернәрсә дә әйтми.
Ул мине кочаклый гына.
– Гафу ит, әбәй, – әйтәм.
– Мин соңга калдым.
Туңдырма эрегәндер инде.

– Мөһим түгел, – әбәй әйтә.
– Иң мөһиме, сине таптык.
Әле биш литр туңдырма
ашап бәйрәм итәрбез инде.
– Филип, син бик пычрак, – әни әйтә.

– Кая идең? – әти сорый.
– Җир астында, – мин елмаям.
– Ничек алай, – әбәйнең исе китә.

Мин Рауфка күз кысам.
Рауф көлә дә, миңа кул бирә.
– Сау бул, Филип, – әйтә.
– Ярдәмең өчен рәхмәт.
Тагын адашсаң, безне килеп бак.

– Филипне тапканың өчен
сиңа рәхмәт, – әбәй әйтә.
– Филип безне тапты, – Рауф әйтә.
– Филип шәп малай.
Сез аның никадәр оста булганын
белмисездер.

Рауф миңа күз кыса.
Әбәйгә, әнигә һәм әтигә кул бирә.
Сакчыларга берничә сүз әйтә.
Аннары туннельгә кире кайта.

– Нигә автопаркка килмәдең? –
әти сорый.
– Мин анда идем, – әйтәм. – Б катында.
– Филип, – әти кычкырып әйтә.
– Әйткәнне тыңларга кирәк.
Мин П каты дидем бит!



**Филип әти-әнисе белән кибетләргә бара.**

**Анда Филип югала. Кинәт караңгы туннельгә эләгә.**

**Филип анда ябылып кала. Туннельдән ничек чыгарга?**

**Караңгыда аның күзенә төрле куркыныч әйберләр күренә.**

1 җиңел тел

978-952-7334-75-1

ISBN 978-952-7334-75-1 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-76-8 (Е-китап, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**